ISSN 0136-7110

ЧАЯН

САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ

THE MAGAZINE OF SATIRE AND HUMOUR

9
1999

CAJAN CHAYAN

КАЗАН

Э.ДЫШАЕВ рәсеме.

И.НӘФИЕВ рәсеме.

Л.БОЧКОВА рәсеме.

Минем беренче шигырем 1952 елда "Чаян"ның 12 санында дөнья күргән иде. Шуннан бирле журнал белән дуслыгым өзелмәде. Менә бүген дә яңа әйбер күтәреп килдем.

АВТОР.

Әхмәт РӘШИТ

ДЕФОЛТ

Әйдәле, энекәш, әйдәле, офисны да күреп кит. "Мерседес-Бенц"ны ошаттың бугай инде. Шәп машина бит, ә?! Бусы — минем эш урыным була. Телевизорлар түгел ул, компьютерлар. Аңлыйсыңмы — компьютер. Исәп-хисапны хәзер менә шундый хикмәтле аппаратлар алып бара. Әтиең генә ул колхоз кәнсәләрендә чалт-чолт чут төймәсен чутылдатып утыра торган иде. Тәки шуны арифмометр белән эшләргә дә күнектереп булмады. Авыл кешесе чут төймәсенә күнеккән шул. Кстати, хәзер пенсиядәдер инде. Ә, шулаймы? Колхозда пенсияне вакытында бирмиләрдер шул. Нишлисең, базар экономикасы, брат... Девальвация... Инфляция... Эмиссия... Аңлыйм, аңлыйм... Элеккечә яшәп булмый, энекәш. Ничек ди әле безнең Президент... Дорогие Россияне... пнимаете, ди... Аңларга кирәк шул, аңларга дөньяның кая барганын... Менә бу компьютерлар безнең фирмага миллионнар китерә. Трансферт дигән нәрсәне ишеткәнең бардыр. Әйтик, Мәскәү безнең өлкәгә ничәдер миллион акча җибәрә. Ашлама сатып алу өчен... Без аны фәлән банкка күчерәбез дә, дивидендны безнең кесәгә керә. Ә теге банк тагын бүтән банкка... Беркем дә алдатмый... Кстати... Сеңелем... Аудит-консалтинг аша белеш әле... Тегеләр безгә бурычларын кайчан кайтарырга җыеналар икән? Заодно таныш бул: бу безнең авыл егете... җидееллык мәктәптә математика укыта... Шулай, энекәш, шулай, колач кирәк, перспектива кирәк. Безнең бу офшор зонада әллә ниләр корып була. Әтиең генә ул керем-чыгым... сальдо-мальдо дип урындык җылытып утыра иде. Акча эшләргә кирәк, акча... Нәрсә? Трактор? Ашлама? Тапкансың кайгыртыр нәрсә? Америкага телекс кына шакылдатабыз... Момент... хәзер төяп җибәрәләр. Безнең холдинг компаниянең алар белән эшләре җайланган. Карале, сеңелем, мистер Джексон номерын җый әле... Һелло, мистер Джексон. Һау а ю? Ай контактет вис Чейз Менхеттен бэнк. Йес.О'кей! Гуд бай! Сэнкию... Аңладыңмы, энекәш? Манхеттен банкы белән элемтәгә кердем, дидем. Бөтенесе тәртиптә, дидем. Ничава кеше ул мистер Джексон, но зверь инде, зверь — үзенә тиешлене алмаса, бугазыннан буып алыр. Но без дә төшеп калганнардан түгел. Үзебез дә капиталистлар белән сөйләшергә өйрәндек. Үзебез дә капиталистлар бит инде. Почти. Президентыбыз әйтмешли: "Дорогие россияне. Пнимаете". Аңлыйбыз. Авыр, конечно, но, аңлыйбыз... Син нәрсә, сеңелкәш, күзләреңне күгәртеп алдыма килеп бастың? Нәрсә? Дефолт? Нинди дефолт?! Ах, имансызлар, мине банкротка чыгарганнар бит болар! Как так? Дефолт дигәнне син аңламыйсыңдыр әле, энекәш! Димәк, бөтенесе бетте... Мерседес та юк, офис та, компьютерлар да юк. Соңгы ыштанымны салдырып алмасалар, бик рәхмәт инде. Шулай да була ул, энекәш. Дефолт дефолт инде ул.

Кайда син, и Карлсон?..

Сыртына бормалы җил канаты — пропеллер выжылдатып очкан Карлсонга рәхәт. Төймәгә басуы була, шунда ук өй түбәләре өстенә үк менеп оча!

Мондый уңайлыклар гади халыкның да эчен төртеп тишмәс иде, әлбәттә. Әйтик, бичараның йорты яна, зинһар, моны кара корымлы мәзәк дип исәпләмәгез. Дөньялыкта йортлар еш яна шул...

Мисал өчен, Биектау районында бер ел дәвамында 120 йорт-ихата дөрләп кабына. Яшел Үзән, Норлат районнарындагы дистәләгән янгыннарны әйтеп торасы да юк — монда көн саен диярлек, "кызыл әтәч" канат җилпи тора.

Җөмһүриятебезнең авыл төбәкләрендә бу туймас "әтәч" елына 1500 тапкыр очып кунып килә тора. Ел саен сыртка төшә торган 10 миллион тәңкәлек зыянны уйлыйсың да, шаккатасың. Җөмһүриятнең янгыннар аркасында күргән зыянын атап әйтү өчен бу санны икегә тапкырларга кирәк.

Сыртында пропеллер бөтерелеп торган Карлсон да "КамАЗ"дагы 1993 елгы янгын сөременнән тончыгып калыр иде. Двигательләр заводының дөрләп януын белеп аһ иттек. Фаҗигале янгынның каян килеп чыкканын ачыклар өчен ничәмә-ничә комиссия көл–корымда кызынды.

Халне ачыкладылар да кебек. Искәрмә, күрсәтмә язулары да языдды.

Янгын ыгы–зыгысы тына төште һәм 1997 елда "КамАЗ" акционерлык җәмгыятендә, һичбер акыллы фикергә сыймас рәвештә, янгын сүндерү гаскәрләрендә хезмәт иткән егетләрне хезмәттән уптым-илаһи читкә аткарырга тотындылар. Янгын сүндерүчеләрнең дүрттән берен эштән алдылар. Югыйсә, янгын сүндерү командаларындагы техниканың саны һәм хезмәттәге кешеләрнең саны тиешеннән болай да бик аз иде.

Сыртындагы пропеллерны Карлсон әфәндегә һәм үзең мәтәштергән насоска гына ышанырга калды. Ә кайнар аш һәм кайнап торган эшләр белән гаять мәшгуль Карлсонның болай да эшләре муеннан иде.

Игътибар иткәнсездер: Казан, Чаллы, Түбән Кама иҗе шәһәрләрдә анда да, монда да күп катлы зиннәтле йортлар калка тора.

Проектлаучы институтларның берсендә безгә болай дип аңлаттылар: мондый йортлар янгынга каршы махсус система куеп төзелә икән... (АППЗ, инәң башы!)

Мондый йортлар күбесенчә торак трестлары һәм идарәләре балансында тора. Аларның акчасы бер пропеллерга, Карлсонга ярашлы бер чалбарга гына җитә. Калган сумманы һава белән өреп кабартып тутырырга туры килә.

Бер Түбән Камада гына да АППЗның өчтән берена техник хезмәт күрсәтелми. Чаллыдагы һәм Казандагы шундый автоматика системаларына махсус игътибар һәм җитди кайгырту, карап тору кирәк.

Әгәр дә мәгәр бу биек йортларны Карлсон пропеллерлары белән тәэмин итмәсәләр, биек йортларда янгын сүндерү техникасын сатып алу мәсьәләсен карарга туры килер.

Кимендә 50 метрга менешле җыелма баскычлар кирәк булыр. Алар исә Казан белән Чаллыда берәү-икәү генә.

Янгыннан саклану гарнизоннарында махсус техника сатып алу өчен акча юклыктан, бу мәсьәләне министрлыклар карамагындагы оешмаларның һәм җөмһүриятебез шәһәрләре администрацияләренең уртак көче белән генә хәл кылырга мөмкин булыр.

Биек йортлар түбәсендә берәр Карлсон утырса һичнәрсәдән курыкмас идек.

Әмма бездә бүген Карлсон да, махсус баскычлар да — дефицит.

М.ХАҖИЕВ,
Р.ЗӘКИЕВ.

Янгын эзе экспонат булыр...

Моннан унбер ел элгәре Татарстан Республикасының Берләштерелгән Дәүләт музеенда янгын чыкты. Шуннан соңгы төзәтү эшләренә акча бүлеп бирелде. Музейны элекке кыяфәтенә кайтарабыз, дип күп вәгъдәләр бирделәр. Әмма вәгъдәләр вәгъдә килеш калды. Вәгъдә ителгән акчалар мөһимрәк объектларны төзү өчен тотылды. Ни белән тәмамланыр бу вакыйга?

Казанда яшәүче һәм журналыбызны даими укучы В.Лентин булачак хәлләрне шигъри рәвештә болай дип гоманлаган:

Анкып тора янгын сөремнәре,
Һичкемнен юк ремонт уенда...
Янгын эзе экспонат булыр
Безләрдән сон килер буынга...

КАРШЫ

Гомуми җыелышта Сафиулланы кол-хоз рәисе итеп сайлау бара.

— Кем дә кем Сафиулланы колхоз рәисе итәргә риза, кулларыгызны күтә-регез! — ди җыелышны алып баручы.

— Ә кемнәр каршы?

Әптән Гәрәе бу юлы да кулын күтәрә.

— Гәрәй Әптәныч, сез бит Сафиулланы рәис булсын дип, кулыгызны бер күтәрдегез. Ә хәзер аңа каршы тагын кул күтәреп маташасыз!

— Үзегез әйттегез бит, кемнәр аңа каршы, дип. Какрас аның йорты минем өемә каршы якта!

ЭЧ

Ындыр табагы мөдире булып эшләгән вакытта, Әптән Гәрәенең эшләрен күзәтү өчен, районнан вәкил килә. Ул «ш» хәрефен «ч» итеп әйтә торган сакау кеше икән.

Ындыр табагындагы чистартылмаган тау–тау ашлык өемнәрен күргәч, ул Гәрәйгә:

— Эчегез начар икән, Гәрәй Әптәныч, — ди.

— Бүген иртән катыкны күбрәк ашап ташлаган идем, эчнең шуңа рәте юк!

КИЛДЕЛЕ–КИТТЕЛЕ

— Гәрәй дус, син ни өчен килделе–киттеле адымнар белән арлы–бирле йөрисең?

— Ни өченме? Синең ише дусларым килделе–киттеле сораулар белән арлы–бирле йөрмәсен өчен!

ЙӨК

— Гәрәй Әптәныч, — ди икән шәһәргә күчеп килгән бер авылдашы, базарда йөргәндә, Әптән Гәрәен очратып, — авылдагы туганнарыма миннән күп итеп сәлам алып кайтып тапшыр, ярыймы?

— Ярар, апкайтырмын, әмма бик күп итеп алып булмас, йөгем шактый мул җыелды! — дигән аңа Әптәныч.

АКЧА

— Гәрәй Әптәныч, — дип дәшә шулай берчакны Сапый, — сиңа шәһәрдә ялган акча тоттырып кайтарганнар, дип сөйлиләр. Ул ялган акчаң бармы соң синең, әйт әле?

— И–и–и, Сапый, Сапый, — ди аңа Әптәныч, башын селки–селки, — син ялганы дисең, хәзерге вакытта чыны да калмады инде акчамның!

ҮГЕЗ КАЙГЫРСЫН!

— Гәрәй дускаем, бер дә борчылмыйсың! Районыбызда сыерлар саны, узган елгыга караганда, егерме процентка кимегән ич!

— Аның өчен мин нишләп хәсрәтләнергә тиеш ди әле? Үгез түгел лә мин!

Нәҗип МӘДИЯРОВ.

ТОКЫМЫ КОРЫГЫРЫ

УТ УЙНАТЫП ЙОКЛЫЙБЫЗ!

Үткен сүз осталарыннан мәшһүр бер юморчы болай дип әйткән, имеш: «Түшәктә ятканда тәмәке тартмагыз! Югыйсә, үз көлегезне үзегезгә үк чыгарып түгәргә туры килмәгәе!»

Казанда яшәүче В.Камаев түшәктә тәмәке тартып яткан һәм дулап купкан янгыннан соң аны шифаханәдә көч–хәл белән коткарып калганнар.

МАЙ УТЫРА ТАМАККА...

Берәү шәһәр базарларында «Крестьянское» дигән атланмай сатып алырга була булуын... Әмма ул атланмайны туглаучы керәстиәнне Рим папасы үзе дисәң дөресрәк булыр иде...

Бу майны гап-гади шәһәр фатирында кулдан гына туглыйлар икән. Менә шундый «май заводы»н милиция Коллектив урамында яшәүче Мөхәммәтханов фатирына кереп тапты. Монда барысы да көйләп куелган: әзер продукцияне кискеч, ябештергеч тәти кәгазьләр һәм бик тә калын маргарин катламы!

Мондый май тамагыңа утырачак, әлбәттә!

САБАК

Гел генә буш хакка энә белән кое казып, белем алып булмый, әлбәттә. Кайбер сабаклар өчен түләргә дә туры килә. Фатир басулар күбәйгәнлектән, милиция фатир хуҗаларын ят кешеләргә ишек ачмаска куша. Шушы сабак та үтмәсә үтми икән адәм балаларына! Зорге урамында яшәүче Абдуллин иптәш ят кешеләрнең берьюлы дүртесенә ишек ачкан.

Бу юлы хуҗа кешегә тегеләр укыткан сабак сигез мең тәңкәгә төшкән — урлаткан малның хакы шул кадәр икән...



ТӨН УРТАСЫНДА УТ ЧЫКТЫ!..

Төн уртасында Кызыл Октябрь урамындагы хосусый йорт пырлап кабынды. Янгынны сүндерделәр. Әкисәүләр арасында пенсия яшендәге хуҗабикәнең гәүдәсе ята. Аңа үндүрт тапкыр пычак белән чәнечкәннәре, буганнары, аскы һәм өске теш казналарын җимергәннәре беленде. Милиция шушы җинаятьне кылган кешене эзли. Шундый сорау күңелгә килә: ә кеше микән соң ул?



ГӨЛ СИБИМ АЛЛАРЫҢА

Сөйгән ярына миллион роза чәчәге бүләк иткән гашыйк хакында җырда гына ишетергә мөмкин. Әмма шундый бер кавалер Казанда пәйда булган икән бит, әй! Сизелгәнчә, бик күп алчәчәк бәйләмнәре юнәтергә чамалаган бу. Ахирыләрен ияртеп, шушы бәндә төн уртасында Чуйков урамындагы чәчәк павильонына бәреп кергән, сатучыга тавыш кубармаска боерган һәм, сукыр тиен дә акча түләмәстән, гөлләп чәчәкләрен розаларны талап алып китеп барган.



С.БЕДОВ.

КАЗАН.

— Ике өер миңа бәйләнә башлады! «Дабай разбурки!» диләр!



— Ни өчен үтердең син мине?
— Белмим... Әнә теге пеләштән сора!

ШӘРЫК КӨРӘШЕ — ХӘТӘР...1

Дзюдо ысулларын беләсең килсә, шәрыкча көрәш секциясенә язылырга кирәк. Фоторәсемдәге күнекмә ясаучы малай да моны бик яхшы белә.

Әмма шушы гади хакыйкатьне аңламаучылар да бар икән шул. Әйтик, Казанның моторлар төзү берләшмәсенең өч эшчесе кәеф-сафа корып алганнар һәм көрәш ысулларын урамда кулланып карарга булганнар. Ялгызы гына барган бер ир–атка һөҗүм иткән болар. Аны дөмбәсләп ташлагач, «спортчылар» тыныч кына китеп барганнар. Ә теге ир–ат шунда ук «02»гә шылтыраткан.

Үзләрен милиция тоткарлагач, «дзюдочылар»ның кикрикләре бик тиз шиңгән. Һәм алар патруль экипажына моннан соң беркайчан да шәрык көрәше белән шөгыльләнмәбез дип ант иткәннәр.

АТАЙ МАЛЫ ТҮГЕЛ — КАТАЙ!

Нишләп бу караватны карлы яланга чыгарып утыртканнар? Хуҗасы өстерәп чыгарып ташламагандыр бит инде аны? Төсле металлдан ясалган бу ятакны кемдер, каяндыр чәлгән, шушында китереп яшергән һәм, әлбәттә, затлы тимер–томыр рәвешендә үтилгә тапшырырга чамалаган, мөгаен. Төсле металл юнәтү–сату күпләрнең канын кайнатты бит инде. Арча районында яшәүче Меценко, Гордеев һәм Машков Казанга килеп төштеләр, канал–насос станциясендәге караусыз яткан тимерчыбык әлүмин кәбилне чамалап алдылар. Ике уйлап тормастан, кәбилнең 80 метрын кисеп алып, аулакка яшереп тә куйдылар.

Әлбәттә, станция озак вакытларга чыгырдан чыкты. Ә чәлдерүчеләрнең моңа исе китмәде — монда яшисе кеше мени алар, дрияномайт?!



БӘХЕТ ФӘРЕШТӘСЕ — «ФЕМИДА»!

Бер караганда, юыртакны һәм зиннәтле машинаны бер тәртәгә җигү мөмкин түгел шикелле. Ә тормышта бүтәнчәрәк була икән шул...

Әнә, күптән түгел генә Юлларда Иминлек Инспекциясе бер машинаны туктатты. Рульдә — Казан кешесе Макаревич. Тентеделәр машинаны. Шахмат уенындагы домино кирпечләре шикелләрәк сәер нәмәрсәләр килеп чыкты — моннан берничә минут кына элгәре урлап–талап чыгылган «Фемида» атлы компьютерлар икән бит алар!

ЧАЯН фото-альбомы

ҖАНЫМ ЖӘЛ ТҮГЕЛ!

Октябрь аенда аласы хезмәт хакы март аенда гына бирелгән бер хезмәткәргә чаянчылар мондый сорау бирде:

— Дүрт ай буена көткән хезмәт хакыгызны талап алырга килгән бәндәгә ни дияр идегез?

— Менә моны тотасың килмиме, дияр идем! (Фоторәсемгә күз салыгыз!)

Шул нәрсә игътибарга чалына: хәләл милкен саклау хакына гражданнарыбыз коралдан да, бандит өермәләреннән дә курыкмый башлады.

Мәсәлән, Казан шәһәренең Тынычлык урамында өч яшь егет бер фатирны ватып кергәннәр. Анда илле яшьлек пенсионер яши икән. Соңгы ярты мең тәңкә акчасын саклап калыр өчен пенсионер каршылык күрсәтергә тотынган һәм угрыларның берсен пычак белән җәрәхәтләп өлгергән.

Альбомны Татарстан Эчке эшләр министрлыгының җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлеге өлкән редакторы Ю.ЗАХАРОВ актарды.

Чаянның СӘХНӘ ТҮРЕ

Бүген безнең бу бүлмәбезгә гүзәл кунак килде. Иң зур хыялын гамәлгә ашырган кыз ул. Зөлфия Шакирова бәләкәй чагында ук актриса булырга хыялланган. Хәзер ул — Татарстанның атказанган артисткасы, эстрада һәм халык җырларына багышланган бик күп затлы бәйгеләрдә лауреат булды, дипломант дигән дәрәҗәләргә иреште. Аның белән хәзер «Чаян»ның махсус хәбәрчесе Петр ШАҺРАЙ сөйләшә.

Җыр уен эш түгел...

Хәбәрче: Зөлфия ханым, үз хыялыгызга илтә торган сукмакларда чәнечкеле үлән сипкән юллар очрамадымы?

Зөлфия: Такыр гына барырдай сукмаклар кайда бар соң ул?! Уфаның сәнгать училищесына укырга керергә теләгәнемне белгәч, әнием тавыш кубарды. Мине сәүдә техникумында укытып чыгарасы килгән иде аның. Әйе, хәзер генә ул бер сатып алучыга — биш сатучы. Ул чакларда исә сәүдә кешесе бик дәрәҗәле исәпләнә иде. Ә мин үз ниятемнән кайтмадым...

Хәбәрче: Керү имтиханнарын ничегрәк тапшырдыгыз соң?

Зөлфия: Чәнечкеле эрәмә арасына кереп киткән шикелле булдым...

Хәбәрче: Моны ничек дип аңларга инде?

Зөлфия: Ялгыз җырлау бүлегенә ун гына кешене кабул итәләр иде. Ә шул бүлеккә керергә теләүчеләрнең саны йөздән дә артык! Шуңа күрә өч тур уздырдылар. Беренче турда Р.Сәхетдинов көенә «Кайтмадылар» дигән җыр җырладым. Нечкә иләктән үттем бугай...

Икенче турга килдем. Сорыйлар:

— Фамилиягез ничек?

Әйттем.

— Барыгыз, һава сулап йөрегез! — диләр.

Кирәксез бәндә булып калганда һава сулап йөреп була мыни инде?

Өченче тур башланды. Курка-курка гына залга күз салам. Мине тагын һава сулап йөрергә чыгарып җибәрәләр. Бусында хәтта фамилиямне дә сорап тормадылар.

Бер көннән соң бәхеткә ирешкәннәрнең исемлеген чыгарып элделәр. Мин дә шул исемлектә! Соңыннан гына ачыклап белдем: беренче турда ук вокал сәнгате бүлегенә кабул ителгән булганмын икән...

Хәбәрче: Сез затлы исемнәргә, призларга, дипломнарга ия ханым. Бүләкләрегезнең кайсы кадерлерәк?

Зөлфия: Күптән түгел генә «Татар җыры» дигән конкурс булып узды. «Гөлҗамал» җырын иң шәп башкаручыларның бәйгесе булды бу. Җиңүчегә махсус бүләк билгеләнгән иде. Өч йөз җырчы чыгып җырлады бу җырны. Һәм шушы бүләкне алган чагымдагы хәлемне күз алдыгызга китерегез!..

Хәбәрче: Иregez Җәвит — талантлы, кызыклы, юмор тоя торган ир. Аның хәләл җефете булу өчен үзенә күрә бер конкурс булмыйча калмагандыр...

Зөлфия: Боларга өстәп шуны да әйтер идем. Ул – режиссер, җырчы, администратор, икътисадчы, шофер, хисапчы, амбар мөдире, сакчы... Уйлап карагыз. Ул «Салават» исемле җыр театры оештырды. Мин шунда эшлим. Шундагы эшләрдән башым чыкмый. Ә сез әйткән сорау мәсьәләсенә килгәндә, шуны әйтим: без кавышкан чакта җиһанда бүтән һичбер кыз да, егет тә юк иде. Дөресрәге, без аларны да, дөньяны да күрер–аңлар хәлдә түгел идек.

Хәбәрче: Сез ирегез белән көнен дә, төнен дә аерылышмыйсыз. Сәхнәдә дә, кибетләрдә дә, киноларда да, эш хәл иткеч очрашуларда да сез һаман бергә. Хәтта кайбер тату парлар хакында «Җәвит белән Зөлфия шикелле болар!» – дип үк әйтә башладылар.

Зөлфия: Ишетәсезме аяк тавышларын? Ирем кайта!

Чынлап та Җәвит кайтып керде һәм шунда ук аңа хатыны сорау бирде: «Без нишләп һәрвакыт бергә?»

И.АЗИМОВ рәсеме.

— Бу дүртенче казаннан сезнең казанга.

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

Хәниф Хөснуллин бик соңга калып кайсыдыр дустыннан "кунак" булып фатирына кайтырга чыккан.

Вакыт сәбәпчеме, әллә тукталышта көзге җилдән бөкшәеп торган Хөснуллинның кечкенә гәүдәсен шәйләп бетерә алмыйлармы – автобуслар һич туктамыйлар, үтәләр дә китәләр икән.

Ачуы кабарган Хәниф Хөснуллин якякка йөгергәли башлый. Күзе тукталышның төрле җирләренә куелган биек чүп савытларына төшә. Савытларны ах-ух килеп аударган бу, аларны тәгәрәтеп юлга аркылы тезеп чыккан. Эшен тәгәлләгәч, канәгать рәвештә кычкырып җырлап җибәргән, аннан күңеленә шом йөгергән: эләктерсәләр?!

Монда да аптырап калмаган, еракта торган багана артына поскан да, тукталышка карап тора икән. Автобуслар "киртә" куелган җиргә җиткәч, туктыйлар, шоферлар сүгенә-сүгенә теге чүп савытларын төрле якка тәгәрәткәләп, китеп баралар икән. Кызган шагыйрь савытларны кире тезеп куя тора.

барып концертлар куясыз. Авылларда буласыз. Авыл халкының хәзер кесәсе такыр. Концертка керердәй билетлык акча табамы алар?

Җәвит: Авыл залларына тамашачыларның хәтта үз урындыкларын алып кереп утырмаган чакларын хәтерләмим. Череп баеганнан тыңлый торган көй түгел бит ул җыр дигәнең. Җанга кирәк бит ул.

Хәбәрче: Сезнең концертларны соңгы вакытларда кайларда шаккатып тыңладылар?

Зөлфия: Күптән түгел генә Уфада концертыбыз булды. Эстрада җырларын, халык җырларын җырладык. Татар, башкорт җырларын... Соңгы аккордлар яңгырап бетүгә мең кешелек зал аягүрә басып безне озак алкышлады. Без уен коралларын җыеп куйдык, кием алмаштырдык, кунакханәгә кайтырга җыендык. Ә тамашачылар һаман алкышлый.

Хәбәрче: Яраткан мәзәгегез бармы?

Җәвит: Ресторанда клиент торт китертә.

Официант әйтә:

Ничәгә кисим? Алты кисәккәме? Унике кисәккәме?

— Алтыга кисегез. Унике кисәкне үк ашап бетерә алмам, мөгаен...

Җәвит: Борынгы аксакаллар әйткән бит: ялгыз кеше – ярты кеше. Бүгенгесе көндә кайсы ирнең йәки хатынның бер-берсенә: «Син минем – икенче яртым!» – дип әйткәне бар икән? Ир белән хатын бер бөтен булырга тиеш.

Хәбәрче: Сез туктаусыз бүтән шәһәрләргә, җөмһүриятләргә

ТАБЫШМАК БИЛ АЛЫШМАК

1. Ике капчык шикәр комы тора — шуның кайсысы Зәйнеке, ә кайсысы Буа заводыныкы?

2. Бер савытта дүрт язу карасы: агы, яшеле, сарысы, карасы...

3. Кертә, кыса, эш эшләтә, чыгарып җибәрә (тол хатын түгел)?

4. Утлар-сулар кичте, дошманнарны җиңде...

5. Биш чыбыкка җиде кош кунган – сайравын тыңлап туймам.

6. Өйләнү ни белән бетә?

7.Радио белән хатын арасында нинди аерма бар?

К.ӘДҺӘМОВ сораулары.

Җаваплар:

1. Зәйнең капчык төбеннән Зәй җоны чыгар, Буаныкыннан – Буа җоны. 2. Ел фасыллары. 3. Дүрт тактлы двигатель. 4. Көмешка. 5. Җиде нота. 6. „У" белән. 7. Радионы сүндереп була.



А.КАЗУНИНА рәсеме.

Хәниф Хөснуллин һәр туктаган автобус саен:

— Туктарсыз, һә, туктамый чарагыз юк. Хәниф туктатыр чара табар ул, әйеме, Хәниф! — дип сөйләнә икән.

***

Хәниф Хөснуллинның беренче китабы чыккач, аны ике язучы дусты теплоходта Казанга барырга үгетлиләр. Имеш, язучылар белән кайнашып алырлар, кемнеңдер күңелен күрергә кирәк, алда янә китаплар чыгарасы бар...

Хәниф Хөснуллинның китапка гонорар алган чагы, ул дәвер өчен бихисап күп акча... Башта Чаллыда "юалар" китапны, бу эш теплоходта да дәвам итә.

... Хәниф Хөснуллин тәненә үрмәләгән салкынга түзә алмыйча уянып китә. Әңгер чак. Күзен уагалап, җәфалана торгач, аңыша —нииндидер сулы канау читендә, пычракта ята икән бит. Кесәдә акча да, документләрен дә юк. Дуслардан җилләр искән. Баш очында җыйнак портфеле аунап ята. Аннан берничә яңа китабы шуып чыгып маташалар. Бераз исәнгерәп утыргач, Х.Хөснуллинның башына иң беренче уй килә: кайда ул?

Үтеп баручы бер хатыннан белә — ул Чистай шәһәрендә "кунак" булып ята икән бит! Х.Хөснуллин эшнең нидә икәнен чамалый инде — "салып" алгач, ул яман холыксызлана башлый, теләсә кемгә бәйләнә, димәк, аны теплоходтан мәҗбүриләп төшереп калдырганнар, дуслары исә, күрәсең, йоклап калганнардыр.

Кайтырга кирәк бит. Х.Хөснуллин пристань янына килеп, Камада әйбәтләп юына. Салмышлык галәмәтләре чигә төшә. Чаллыга бер ракета китәргә торуын белгәч, ул шунда ыргыла. Кулында — яңа китабы. Кизү торучы матроска ялынып, әчкә үтә, капитанны эзләп таба һәм хәлен сөйләп бирә. Бәхеткә каршы капитан татар кешесе, җитмәсә үзе дә шигырьләр яза икән...

— Чаллыга кадәр капитан каютасында ашап, эчеп, чын кунак булып кайттым, — дип сөйли иде Хәниф абый көлеп.

Фәкил САФИН.

Илфак ШИҺАПОВ

(Хикәя)

Музейга бина итеп мәрхүмә Сәкинә əбинең, сугышка кадәр салынса да, əле таза гына торган өе билгеләнгәч, авыл халкы бер-бер артлы иске әйберләрен китерергә тотынды.

Башлап Түбән оч Җәүдәт әле революциягә хәтле староста бабасы утырып йөргән тарантасның ничектер сакланып калган алгы тәгәрмәчен китерде. Шуннан китте эшләр хутка: кайсы йон кабасы, кайсы әбисе тукыган палас, кайсы иске чүлмәк ташый... Югары оч Мөкәрәмә әби кыз чагындагы чулпыларын да биргәч, музей бөтенләй ямьләнеп китте.

Бер ел дигәндә музейның ике бүлмәсе дә шыплап тулган иде инде. Нәрсәләр генә юк иде монда! Сәетгалиләрнең гөбесе, Карун Гыймадиларның талчыбыктан үргән кәрзиннәре, Зөһрә әбинең калфагы, Закирларның иске агач караваты, тагы әллә нәрсәләр...

Музей эшли башлагач килгәләүчеләре дә күренгәли башлады. Хәтта күрше авыллардан узган-барганнар сугылгалый торган итте. Бервакыт район гәҗитеннән килеп төштеләр. Шуннан соң китте күрше авыл мәктәпләреннән көтү-көтү экскурсия килү!

...Бөтен эшне базар икътисады бозып ташлады! Кибетләрдәге яңа бәяләр авыл халкының башына күсәк белән органдай итте. Товарлар арзан чакта да акчасын җиде кат санап кына туздырырга гадәтләнгән кешеләр кибеттән әйбер алмас булды... Күбесе чормалардан, чоланнардан иске-москыны эзләп табып, ямаштырып-рәтләштереп, кабат куллана башлады. Бәяләр күтәрелеп күпмедер вакыт үткәч, музейга беренче төзәлмәс яраны Аю Шакир ясады. Аягындагы чүчинкәләрен дә салмыйча, лап-лоп басып килеп керде ул. Керде дә берни дәшми генә пырдымсыз рәвештә түргә узды. Үзе моннан ике ел элек китергән дүрт аяклы бәләкәй агач эскәмиягә беркетелгән иске сепараторын култык астына кыстырды да ишеккә таба юнәлде.

— Рәшит энем! — диде ул мөдиргә карлыккан тавыш белән. — Гаепләмә инде! Теге электрически сепараторыбыз ватылды. Бер атна түздек каймаксыз... Бүтән булмый! Аның бит яңасы кибеттә дә юк. Булса да без ала алмыйбыз аны хәзер. Алам инде мин бу инәдән калган калтырчаны!

Икенче булып Саңгырау Гамир килде. Сөйләнә-сөйләнә үзенең агач җилпучын әләктерде...

Тотынды халык әйберләрен кире ташырга. Берсе: “Идәнгә җәяргә нәрсә калмады“, — дип, иске паласларын алды, икенчесе: “Ут эш бетә башлады“, — дигән булып, җиз самавырын салып китте. Хәтта Мөкәрәмә әби дә килеп, көмеш чулпыларын таләп итте. Шәһәрдән кайткан оныгы йөдәткән икән. «Хәзер аның берсе-берсе биш йөз сум тора!» — дип әйтә, имеш, ул кызый! Һәрхәлдә, әби Рәшит алдында шулай акланды. Закирның хатыны, ат җигеп килеп, иске агач караватларын салып алып китте. «Яңа өйләнгән малайларга ярар әле, кибеттә яңасы биш мең тора бит!» — дип зарланды хатын. Башкасын сөйләп торасы да юк. «Каз оясына ярар шунда», — дип иске тал кәрҗингә кадәр сыпырттылар... Шулай итеп, музей әкрен-әкрен генә таралып бетте, түрдә Җәүдәтнең тарантас тәгәрмәче белән Рәшитнең иске читекләре генә эленеп калды.

Ишек артында ишетелгән кыштырдау аны сискәндереп җибәрде. Ул тиз-тиз атлап барып ишекне ачты. Анда әллә нинди уңайсызланган кыяфәттә Җәүдәт басып тора иде. Ул Рәшиткә карамыйча гына:

— Сәкинә әбинең Ташкенттагы кызы телеграмма суккан. Бөтенләйгә авылга кайтам, инәйнең өен бушатсыннар, дигән. Минәйтәм, теге тәгәрмәчне алыйм әле югалганчы!..

ЛЕНИНОГОРСК шәһәре,
ТАТАРСТАН.

Р.АБЗАЛОВ рәсеме.

В.КОСМЫЛИН рәсеме.

— Без сезне музыкага өйрәтер өчен ялладык! Арифметикага түгел!



Фәрит Вахитов

Фәрит ВАХИТОВ нәкъ гасыр уртасында,1950 елда туган егет. «Чаян»да күптән эшли. Темалар уйлап таба, карикатуралар ясый. Көлкегә бик хирыс Фәрит. Көлә-көлә СССР рәссамнәр союзы әгъзасы булды, «Чаян»ның бик күп күргәзмәләрендә үзен һәм иҗатын яхшы яктан танытты.



ЧАЯН альбомы

33

Кадерле укучым!

Син, әлбәттә, «Чаян»дагы альбом өлешләрен җыя башлагансыңдыр. Игътибарлы бул: һәр санны теркәп барсаң 2000 ел уртасында синең кулыңда беркемгә тәтемәгән шәп альбом булыр.

Монсы сиңа мәгълүм булды. Шуны да искәртәбез — әгәр редакциягә альбомда катнашачак рәссамнарның исемлеген беренче булып җибәрсәң, редакция сине бүләкләячәк.

Ипи Шүрлегенне

***

— Әти, хәрәмсарай агасы дип кемнәрне әйтәләр ул?

— Шәхси коралын югалткан солдатларны, улым!

***

—Рядовой Маратов, бер адым алга! Самоволкадан тагын лыкынганчы эчеп кайткансың. Шушы эчүең булмаса, күптән сержант буласы кеше бит син!

— Исем китте ди сержантлыкка! Берәр стакан җиффәрсәм үземне генераллар кебек хис итәм мин!

***

— Прапорщик! Күрәсеңме минем погоннардагы йолдызларны?! Бик беләсең килсә, мин аларны күк капусыннан чүпләмәдем!

***

— Офицерлар каршында өч хәрефле сүзләр белән сүгенеп торганың өчен карцерда өч тәүлек утырып чыксаң — калган хәрефләрне дә онытырсың.

***

Маршаллар шикелле пенсия алу турында хыялланмаган генерал — генерал түгел ул!





ЧАТ БАШЫНДА — ХАТ БАШЫ

ИКЕ БАШЛЫ МУТАНТ

Кинәт кенә үсте бәя
Ипиләргә, сөтләргә.
Бабайларга, әбиләргә
Инде хәзер нишләргә?

Лаеклы ялга чыктылар
Әбиләр һәм бабайлар.
... Кибет ишеге алдында
Теләнеп йөри алар.

Кемгә кирәк, кем кайгыртсын
Картларның мәнфәгатен? —
Ямау өстендә ямау бит
Дәүләт кадәр дәүләтнең!

Ике башлы мутант сәмругъ
Үз оясын җимерә,
Илне сатып яңа буржуй
Ананасын кимерә...

Ринат НУРУЛЛИН.

БИЕКТАУ районы,
КОНСТАНТИНОВКА авылы.

Рафаэль Габделхәкимов

Рафаэль Габделхәкимов олы белемле рәссам. Казан сәнгать училищесын тәмамлагач, ул Ленинградның югары сәнгать училищесында укып кайтты. Белеме юан меңне егар диләрме әле? Рафаэль нәкъ шундыйлардан. Ул юморны, «Чаян»ны бик ярата. Журнал өчен көл-келе рәсемнәрне 1967 елдан бирле ясап килә.



— Гафу итегез, икәүмени алар?

— Мәктәпкә бармыйча ярамас, сиңа бөтенләй «нуль» билгесе куйганнар бит монда!

ЧАЯН альбомы

35

ИСКИТМӘЛЕ

Һай, китте лә чуар заманалар,
Кая бакма — шунда бозыклык!
Дөньясының асты өскә килде,
Тормышта бер мәгънә,
кызык юк.

Түрә булды җыен әхлаксызлар,
Ике йөзле сатлык адәмнәр;
Алды сырып безнең хакимнәрне
Карьерачы әтрәк-әләмнәр.

Талый шулар, нахал өер булып,
Халык тапкан хәләл мөлкәтне;
Урын өчен тартынмыйлар хәтта
Сатудан да газиз милләтне!

Эте булып бер-берсенең, шулар
Ирешәләр данга-шөһрәткә:
Бирелә гел һаман шундыйларга
Олы титул, затлы бүләк тә!..

Искитмәле... Шулар хакимлектә,
Карый торгач бары үз җаен,
Тотындылар данын төшерергә
Милләтебез күрке Тукайның.

Ертлач этләр урын били һаман,
Яшәешнең ямен бетерә;
Бер тиенлек файда урынына
Мең тәңкәлек зыян китерә!..

Заһид ФӘЙЗИ.

КАЗАН.



— Кысанын кысан, әмма фатир диңгезгә карап тора.





— Инде тозлы кыяр белән тозлы кәбестә дә булса!..

Бала-чага

ПОЧМАГЫ

Кызый мәктәптән сөенеп кайтып керә.

— Әни! Безгә бүген прививка ясадылар!

— Авырта, дип, еламагансыңдыр ич, балам?

— Юк! Алар мине куып тота алмадылар!..

***

Әти–әнисе балалар бакчасына кереп Кирамның ничек уйнаганын үз күзләре белән күрергә тели. Беренче каттагы «Әйбәт балалар» дигән бүлмәгә керсәләр — Кирам күренми. Икенче катның «Тәртипсезләр» дигән бүлмәсендә дә юк Кирам. «Иң начар балалар» дигән бүлмәдә дә булмагач әти–әнисе дүртенче катка менеп карый. Ә анда — кыңгыраулы тимер ишек, ди, ишеккә: «Кирам» дип язылган ди...

***

Урамда уйнап йөргән җиреннән Вәли баганага бәйләнгән бурзай янына килеп аның койрыгын сыйпый башлый. Әнисенең коты алына.

— Улым, нишләвең бу?! Тешли бит хәзер үзеңне!

— Юк, әни, мин бит аны тешли торган ягыннан сыйпамыйм!

***

Алмазның туган көненә ташбака бүләк итәләр. Ул аның ничек йөргәнен көне буе карап утыра. Ахыр чиктә түзми, әйтеп куя:

— Ә хәзер түбәсен салдырыгыз, мин аны сыйпап карарга телим.

Реклама тортмә телләр өчен һәрвакыт бик шәп мишень булды. Үзгәртеп кору чорларына кадәр үк мин Казан рестораннарына барган чакта менюларны чәлдереп чыгарга ярата идем. Ул чакларда язылмаган бер закон бар иде: фирменный ризыкларга ресторанның үз исемен кушарга гадәтләнделәр. Менюларның берсенә акка кара белән болай дип язылган иде: "Шампурга элеп кыздырылган кош — "Акчарлак". "Чайка" авторы Чехов белән Станиславский моны белсәләр гүрләрендә әйләнеп ятарлар иде, билләһи! "Яшьләр үзәге" ресторанынннан алган менюда болай язылган иде: "Яшьлек" камырына төреп кыздырылган чучка ите".

Болар узгандагы хәлләр инде. Бүген исә янып торган, безне һәр яктан чолгап алган рекламадан зәвыксызлык аңкып тора. Шуңа пародия иҗат итәсе килә. Андый әкәмәт рекламаларны махсус эзләп йөрисе дә юк. Казан урамнарын бер урап үтсәң дә җитә.

Әнә, троллейбус бара. Бортына янып торган кызыл хәрефләр белән язып куйганнар: "Барысын да кадрлар хәл итә!" Шайтан алгыры, Зюганов Думада шулкадәр ныгып урнашып, "мыеклы Сулико"ның идеяләрен күрәләтә пропагандаларга тотынганмы әллә?! Әмма бераздан тынычландым. Баксаң, "Коника" фототасмасына реклама икән бит бу... Сәясәтнең һичбер катнашы юк! Матур сүз хакына газиз әткәсен дә кызганмас, дигәннәре дөрестер, күрәсең. "Халыклар әткәсен" дә кызганып тормаганнар хәтта!..

Гомумән, ике мәгънәле фикердән совет чорында никадәр курыккан булсалар, хәзер ул бүгенге рекламаның хәтта ки мәҗбүри бер атрибутына әверелде. Тукай мәйданында балкып торган плакат безгә кычкыра: "Сиражин һәм К° һәркемгә мөлдерәтеп бүлә!" Монда буяулар һәм лаклар хакында сүз барса да, кешеләрне

Шашлык тәме

миңгерәйтерлек итеп әйтелгән ләбаса! Минемчә, алкашларның күбесе шул плакатта язылган адресны эзләп йөгерәсе килгәндер: чынлап та мөлдерәтеп бүлеп бирүләре ихтимал бит!

Чернышевский урамына барып кердем. Һәм, үзем дә сизмәстән, "Интернационал"ны җырлый башлаганмын: "Без азатлыкка ирешербез, ә паразитларга ирек тәтемәс!" Юк, моңа "Нишләргә?" дигән мәңгелек сорау куйган ялкынлы революционер гаепле түгел. Бер йортның фасадына: "Паразитларга яшәргә ирек бирмәбез!" — дип язып куйганнар. "Бәй, мин әйтәм, — тагын эшләмичә яши торган соры кортларга каршы сугыш игълан иткәннәр мәллә?" Әмма, якынрак барып карагач, яңа революция куркынычы янамаганын аңлап алдым. "Санитар" дигән кибет әнә шулай иплән кенә кимерүчеләргә каршы агу тәкъдим итә икән!

"Topjoy" ширбәте рекламасы шәһәрдә йөрүче күп автобусларга ясап куелган. Мин аны һич тә аңлый алмыйм. Үзегез уйлап карагыз: тропик җиләк-җимешләр фонында өч сүз балкып тора: "Хорошее еще лучше". Ягъни, "Яхшы тагын да шәбрәк". Нинди телдә бу?! Сүзләре таныш, ә мәгънәсен һич аңларлык түгел.

Бу сорауга бер дустым җавап тапты. Без аның белән Эсперанто урамын узып бара идек. Шул ук ширбәтне әчәргә кыстаган гаҗәп зур плакат тора. Анда шаккатып калган бер малай, көпшә куелган ике кап ширбәтне сузып тора. Монда да әлеге серле өч сүз язылган.

— Ничек уйлыйсың, ни аңлата икән бу сүзләр? — дип сорадым дустымнан.

— Бәй, берьюлы ике каптан чөмерсәң, ширбәт сиңа тагын да шәбрәк булып тоелачак!

Дусның фикере белән килешергә туры килде. Чөнки моны бүтәнчә һич тә аңлатып булмас иде.

"Фобос" фирмасының Каюм Насыйри урамындагы ваклап-күпләп сату кибетендә кызык бер хәлгә тап булдым. Бер ханым обойларга, бизәгеч плитәләргә карап торды-торды да әйтеп куйды:

— Ай-һай үстергәннәр бәһаләрне, котың очарлык! Өркегеч бу, валлаһи газим! Бәһаләрнең бүтән шопларга караганда әллә ни артык түгеллеген белгәнгә күрә елмаеп куйдым. Бу хатын үзе дә белмәстән кыек атып туры тидерде бит, әй! Мәктәптәге астрономия дәресләрендә бер нәрсә хәтергә сеңеп калган: Сугыш Аллаһысы Марс планетасының ике иярчене бар — Фобос һәм Деймос. Ягъни, Курку һәм Өркү. Шулай булгач, үз кибетеңә "Страх" ("Курку") дип исем кушкансың икән, халыкның синең кибет тирәсеннән табан ялтыратуына гаҗәпләнмә!

"Балалар дөньясы" ("Детский мир") кибетендә видеокассеталар куелган витрина каршында аптырап басып торам. "Үлемнең чырайлары" дигән укшыткыч фильмга өстәмә рәвешендә "Көчләп үтерүләр" дигән яман фильм пәйда булган!

Шундый сорау бирәсем килә: "Көчләмичә үтерүләр дә бар мыни бу дөньяда?!" Бу сорау артык каты яңгырар иде. Шуңа күрә, бүтәнчәрәк әйтеп карыйм:

— Кассеталарга язылган "Шокоменталь видео" дигәнегез ни аңлата?

Сатучының җавабы бик гади:

— Мондый укмаштырган җөмләләрне укыган һәркем шокоменталь хәлдә калыр!

В.ФЕОКТИСТОВ.

И.НӘФИЕВ рәсеме.



В.ФЕДОРОВ рәсеме.

***

— Хезмәт хакыгыз күпме?
— Җан асрарга җитә.
— Әгәр йөз тапкыр күбрәк бирсәләр?
— Ул чакта мин тынычлап үләр идем...

Америкада электроника күргәзмәсендә сорауларга җавап бирүче робот күрсәтәләр. Бер инглиз кешесе:

– Аппаратыгызның ничек төгәл эшләвен хәзер тикшереп карыйбыз, – дип һаһаһәле елмая һәм шундук роботтан:

– Хәзер минем эти нишли? – дип сорый.

Роботның төрле төшендә утлар ялт-йолт янып ала да ул: "Сезнең этиегез хәзер Темзада балык тота", – дигән язулы тасма чыгара.

– Машинагызның ялгышасын белеп тордым! – дип тантана итә инглиз кешесе. – Минем этинең секретаре бүген миңа менә нинди телеграмма җибәргән: "Лорд Бартелл кичә Ницца курортына самолетта очты".

Операторлар аптырап калалар, шулай да кабат тикшереп карарга булалар.

Инглиз җавабын кабатлый:

– Хәзер минем эти нишли?

Робот мондый җавап бирә: "Лорд Бартелл Ниццага очты. Ә сезнең этиегез Темза елгасында балык тота".

***

Ике дус мунчага баралар. Чабыну бүлмәсендә болар өч шешә аракы чөмерәләр, әмма күңелләре күтәрелми. Берсе:

– Карале, дускай, – ди, – моннан ерак түгел генә минем бер танышым яши. Аның спирты Казанның Коры елгасын тутырырлык. Әйдә, киттек шуларга!

Баралар. Ишек шакыйлар. Хуҗа чыга.

– Сәлам, егетләр. Мунчадан кайтышыгызмыни?

– Ә син ничек белдең?

– Шәп-шәрә ич сез! Кулларыгызда – тас!

***

– Официант, буфет янында нинди кәмит ул?

– Бездә шундый йола инде – ресторан ябылыр алдыннан шикаятьләр дәфтәрен кычкырып уку оештырыла.

***

Төрмәдә тикшерү вакытында тоткыннар үзләренең гаепсезгә утыртылуларын төкерек чәчә-чәчә расларга тырышалар. Тик берәү генә:

– Мине караклыгым өчен бик хаклы китереп тыктылар монда! – дип дөп-дөресен әйтә.

– Хәзер үк чыгарып җибәрегез үзен! – дип әмер бирә тикшерүче инспектор. – Югыйсә, ул мондагы намуслы кешеләргә начар йогынты ясарга мөмкин!

***

Бөгелмә аэропортында бер агай самолетка сарык алып кермәкче була.

– Самолетка сарык төягә ярамый! – дип кисәтә стюардесса.

– Сарык түгел бу. Күчтәнәч бу. Ә минем сарык Казанда укырга керергә имтихан бирә! Шунда барышым...

В.БИБИШЕВ рәсеме.

В.ФЕДОРОВ рәсеме.



А.АЛЕШИН рәсеме.

Д.НИКИТИН рәсеме.

А.САЛТЫКОВ рәсеме.

А.ШУЛЬПИНОВ рәсеме.



— Мин сиңа күпме акча түгәм, ә син, җитмәсә, телефон аша секс белән шөгыльләнеп чумара эшли башлагансың!..

СЕБЕР ЯҺҮДЛӘРЕ БӘЙРӘМЕ

Яһүдиләр үзләре аны «Краснояр могҗизасы» дип атыйлар. Хәлбуки, Красноярның дин әһеле (раввины) Иман Глик һәм дини җәмгыять рәисе Яков Бриль тырышлыгыннан башка бу могҗиза була алмас иде. Әмма ул булды. Себер харитасында яңа гыйбадәтханә барлыкка килде. Гыйбадәт кылучыларга бинада урын җитмәсә дипме, ишегалдын киң вә унайлы итеп ясаганнар.

Гыйбадәтханәне ачуда казанлылар да катнашты. Йоланы үтәгәннән соң Л.Сонц җитәкчелегендәге Казан «Симха» ансамбле филармония бинасында концерт куйды.

«Краснояр могҗизасы»н Көнбатышның мәгълүмат чаралары да киң яктыртып, анда аз санлы халыклар: шул исәптән яһүдиләр турында кайгыртканы өчен Рәсәйгә рәхмәт сүзләре күп булды. «Хәзерге вакытта Рәсәйдәге яһүдиләрнең дини җәмгыятьләрендә мөһим һәм, әйтергә кирәк, бөтен бер дәвер тәшкил итә торган үзгәрешләр, вакыйгалар шундый күп ки, хәтта барысын яктыртып бару да мөмкин түгел», — дип яза журналистлар. Мәсәлән, Иерусалим мэры Эдхуд Ольмерт Самарага үз өенә кайткан сыман килеп чыкты. Эш һәм дипломатия максатларыннан тыш, ошбу шәһәргә килү өчен Ольмерт әфәнденең янә дә бер сәбәбе бар иде. Эш шунда ки, Самарада кайчандыр аның әтисе яшәгән.

ДӨНЬЯ КИҢ УЛ...

— Мин төне буе Казаннан Мәскәүгә килдем һәм үземне яңадан Казанымда кебек итеп тоям. — Минем белән очрашу вакытында Татарстан мәгариф министры урынбасары Илсур Һадиуллин гаҗәпләнеп әнә шулай диде. Эш шунда ки, ул Мәскәүнең 318 нче балалар бакчасында булган, ә анда татар балалары үз ана телләрендә сөйләшәләр, татарның гореф-гадәтләренә өйрәнәләр икән.

Директоры Ләйлә Гыйрфанова булган 1186 нчы мәктәп шулай ук күңелдә әйбәт тәэсир калдыра. Бу мәктәпне тәмамлаучы татар яшьләренең күбесе зур урыннарда эшлиләр.

Гомумән, Рәсәй башкаласының һәр округында әнә шушындый татар үзәкләре оешкан. Мәскәүдә немецләр, яһүдиләр, грузиннар, украиннар, поляклар, дагестанлылар, әзәриләр, әрмәннәр, кореялылар, литвалар һәм башка милләт кешеләре үз телләрен өйрәнәләр. Һәм, әлбәттә инде, биредә «Пересвет», «Русская школа», «Русь», «Преображенское» шикелле русча белем бирү юнәлешендәге үзәкләр дә нәтиҗәле эшли.

Әйе, күпмилләтле Мәскәү күге астында барыбызга да урын җитәрлек. Кемнәрдер тарсынмаса, шагыйрь әйтмешли, дөнья матур, дөнья киң ул.

ЭФИРДА «КЫЗЫЛ КҮПЕР»

Әзәриләр, грузиннар һәм әрмәннәр акча эшләү өчен Рәсәйгә киләләр. Йә ата-аналары фатирларын балаларына калдырып, үзләре Мәскәүдә эшлиләр, йә, киресенчә, Рәсәйгә киткән балалары картларга акча җибәреп, ярдәм итеп торалар. Әлеге Кавказ республикаларында халык саны кимүгә йөз тота.

Менә шушы Кавказ якларыннан килгән кешеләр берләшергә нияте кылдылар. Хәтта үз акчаларына «Кызыл күпер» дип аталган радиопрограмма оештырдылар. Шундый исемдәге программа Кавказ тауларында да эшли. Ул өч республикага: Әзәрбайҗанга, Әрмәнстанга һәм Грузиягә хезмәт күрсәтә.

«Кызыл күпер» радиостанциясе 810 диапазонлы урта дулкыннарда эфирга чыга. Аның тапшыруларын Мәскәүдә һәм үзәк Рәсәйдә тынлап була.

Геннадий ЦЕПУЛИН.

Чәй урынына «мәй»

Грузинский чәй чәйнектә,
Өстәлдә башкорт балы.
Каршыңда утырган җаның —
Сиңа ни кирәк тагы...

Чынлап та, җанашың белән самавыр янында чөкердәшеп утырудан да артык берни юктыр бу дөньяда. Ә бит күптән түгел генә мондый ләззәтне татыр өчен өйгә кайтып йөрүнең дә кирәге юк иде. Бауман урамының берничә урынында, җаның теләгән чакта кереп, хуш исле чәй эчеп чыгарга була иде. Һәм болай гына түгел — өрек, йөзем, чәк-чәк белән...

Ләкин заманалар кинәт кенә үзгәрде дә куйды. "Базар мөнәсәбәтләре" дигән шыксыз нәрсә белән тормышка яңа "гореф-гадәтләр" килеп керде. Ә чәй урынына "мәй" белән сату итүнең файдалырак икәнен күпләр абайлап алды.

Башкаланың горурлыгы булып саналган "Татар ашлары йорты" тиздән телеңне сындырырлык "Ресторанно-гостиничный комплекс" дигән исем белән атала башлаячак. Хәзергә әле ул төзелеп бетмәгән, ләкин аның үзенең затлы ишекләрен кем алдында ачасын бүген үк әйтергә була инде.

"Үзгәреш чорының" ачы җилләре урамның каршы ягындагы атаклы "Чәй йортын" да читләтеп үтмәде, әлбәттә. Күпләрнең күңеленә хуш килергә өлгергән чәйханә хәзерге вакытта гади кафе-ашханәләр, киштәләре "тәти" шешәләр белән тулган "БАР" сыйфатында көн итә. Хәтта Бауман һәм Астрономическая урамнарының почмагында урнашкан "Чәй" кибете дә үзенә исем биргән эчемлек урынына төрле колбаса-аракы ише товар белән сәүдә итүне артык күрде. Хәзер инде монда татлы нигъмәтләр белән чәй эчү дигән нәрсә истәлек булып кына калды. Дөрес, бу турыда искә төшереп торучы тагын бер нәрсә бар. Ул да булса — кибетнең "заман рухына" яраклаштырып үзгәртелгән исеме — "PEPSI — ЧАЙ — PEPSI"...

Шәһәр буенча алсак, мондый мисалларның саны юктыр, бәлки. Ләкин болай да бүгенге бетмәс-төкәнмәс үзгәрешләрдән башы әйләнеп беткән укучыны ялыктырасы килми. Һәм, аның өстенә, безнең халык бит ул "сырлы" түгел — чәйне өендә дә ясап эчә ала. Ләкин шуны беләсе килә: халыкка хезмәт күрсәтү турында шаулап йөрүчеләр бу турыда нәрсә уйлый икән?

Р.ГЫЙМАЗЕТДИНОВ.
КАЗАН шәһәре.

Ребус

Әгәр бу ребусны дөрес чишсәгез, мәңге искерми торган халык мәкален укырсыз.



Төзеде Р.АБЗАЛОВ.

КАССА БАСУ

Җинаять кылынган төшкә опергруппадан соң ук инспектор Эркен Пуаруллин килеп төште. Шаһитне — фирма хуҗасының урынбасарын тыңлады.

— Офистан чыгып киткән иң соңгы кеше мин идем, — диде теге. — Коридордан барышлый игътибар иттем: касса бүлмәсендә ут янып тора. Ишекне бераз ачып карау белән үк чамалап алдым. Эшләр шәптән түгел. Сейф ачык, бөтен документлар идәндә таралып ята.

— Сәгать ничәдә булды бу хәл? — дип сорады инспектор.

— Нәкъ шул мәлдә дивардагы сәгатькә карап алдым. 18 сәгать 10 минут иде. Кул сәгатемә дә күз төшердем һәм дивардагы сәгатьнең 3 минутка ашыкканын күрдем.

— Без җинаять кылынган урынга җиденче яртыга килеп җиткән идек инде! — дип өстәде опергруппа башлыгы.

— Сез сейф янына якын килдегезме? — дип тагын сорау бирде Эркен.

— Ничек инде?! Мин бүлмәгә аяк та басмадым! Монда нинди эш кылынганын аңладым да, ишекне ябып, йозагын биклэп куйдым һәм сезгә шылтыратырга йөгердем.

Пуаруллин шаһитне чыгарып җибәрде һәм милиция майорына болай диде:

— Урлашуда моның катнашы бармы, юкмы — әйтә алмыйм! Әмма ул күрәләтә алдаша!

Инспектор нидән шикләнгән?

ЧАЯН чәйханәсе

МЕНЮ

Беренчегә
РЕБУС

Икенчегә
БАШВАТКЫЧ

Өченчегә
ПАЛИНДРОМНАР

Десерт
МӘЗӘК



Кире кериК

Палиндромнар конкурсына карата кызыксыну һич тә кимеми. Алдан да, арттан да бертөрле укыла торган "ике башлы" фразалар төзү күпләрнең күңеленә хуш килде. Бу юлы сезгә үзенең рәсем–палиндромнарын Ринат Абзалов тәкъдим итә.

***

— Мин бүген эчмәскә булдым әле, — ди бер әлкәш шешәдәш дусына. — Аракыга аллергия башланды миндә — аз гына артыгын эчүем була, бөтен тәнем күгәреп чыга...

— Аңлыйм сине. Минем хатынның да йодрыклары бер-берсе потлы гер чаклы!

ҖАВАПЛАРЫ 19 нчы биттә

Безнеке!

Шундый сүзләр йөри: Питрәч төбәгенең атаклы Шәле авылында үтә калку бер урын эзлиләр икән. Бу урын затлы булырга тиеш. Чөнки анда журналистларның “Бәллүр каләме“ бәйгесендә мәртәбәле лауреат булып җиңеп чыккан Мәгъсүм Гәрәевкә бронза бюст куелачак икән...

Һәм бу сүзләр гамәлгә ашмыйча калмас. Чөнки Мәгъсүм Гәрәев бер талпынуда ук журналистлар бәйгесендә алга ыргылып чыкты, бәйге бүләген алды. 1998 елдагы иҗаты өчен “Бәллүр Каләм“ аңа бирелде.

Мәгъсүм Гәрәевнең бәллүр каләме 1999 елда да елкылдый тора. Киләсе елларда кемнәргә бүләк бирәсен чамалаган яңа жюри бу хәлне онытмасын.

Мәгъсүм Гәрәевне өендә туры китерүе бик кыен. “Чаян“ йомышы белән ул җөмһүриятебезнең төбәкләрен айкап йөри, республикада чыга торган барлык гәзит-журналларда һич тә күтелмәгән хәлләр хакында саллы ит-терәп язып чыга.

Ул безнең редколлегия әгъзасы, “Чаян“ның бүлек мөдире. Якташлары — Шәле халкының дәрәҗәсен нык тота. Кыскасы, кемнеке дип сорасагыз, ул — Безнеке!

Рәшит ЗӘКИЕВ.



Фотода: М.ГӘРӘЕВ (сулда) дусларча әңгәмә кора.

ТЕЛЕГРАММА

Казан. Декабристлар ур.2.
ЧАЯН

Хөрмәтле МӘГЪСҮМ ГӘРӘЕВИЧ!

Иҗатыгызның бөтенхалык күләмендә бәяләнүе белән тәбрик итәбез...

Балык Бистәсе районы
хакимияте башлыгы
Равил Хәйруллин.

Салисә ГӘРӘЕВА

Мәгъсүм абый ГӘРӘЕВка

Дөньядагы иң шәп егет
Безнең Мәгъсүм абыйдыр,
Президенты, спикеры —
Бары да аны таныйдыр.

Белəгендә келт-келт итә
Шәймиев сәгатьләре,
Мактана һәм нотык тота —
Шәп аның гадәтләре.

...Заманында ул кызларга
Куркынычлар тудырган,
Йөрәкләрен мәхәббәт һәм
Яшьләр белән юдырган.

Будапештта мадьярлардан
Чәй пешерткән татарча,
Аны белә минзәләләр,
Теләче, Буа, Арча.

Йөри Мәгъсүм, сәфәр чыга,
Районнарны урата.
Үзе яза, янып эшли —
Мактаганны ярата.

Мин дә мактыйм:
(ул үзе дә
Шәп мактана, сабакы!)
Аның өстәл эчләрендә
Бар коньяк һәм аракы...

Юмарт ул, чәе, конфеты —
Өстәленнән өзелми.
Аңа керсәм,
Шәп бер кунак
Итеп сизәм үземне.

Кулын кысам, рәхмәт әйтәм,
Котлыйм бәйрәме белән.
Саф йөрәкле Гәрәевкә
Саф йөрәк белән киләм.
Чөнки мин үзем дә...
Гәрәевләр затыннан.

Аскольд БУЛАНОВ

КҮК ҺӘМ ҖИР

Ресторааннан исереп
Килеп чыкты бер Карга.
Кагынып канатларын
Омтылды ул очарга.

Шактый озак җилпенде,
Тик чыкмады берни дә.

Бик нык ачуы чыгып,
Төкереп куйды җиргә:

— Нигә азапланам соң?!.
Җор юләр инде менә! —
Әй, чукынып китсен күгә! —
Кайтырмын җәяү генә!..

ЭШЛӘР ЧАК ҖИТМӘГӘН

— Нишләп болай бер җирдә дә
Эшләмисең, Әхмәт, син?!
— Эшләр чагым җитмәгән лә —
Кечкенә бит әле мин!

— Кигән чалбарың кыска бит!..
Бераз акыллырак бул!
— Үземнеке түгел лә!
Әти чалбары ич ул!..

УЕН * 99

Конверт һәм маркаларга хаклар бертуктаусыз үсүгә карамастан, безнең конкурс укучыларыбызда зур кызыксыну уятты. Денис Никитин рәсемендә сурәтләнгән тормышчан хәл, әлбәттә, ир-егетләрне дә, хатын-кызларны да битараф калдырмады.

Беренче җавап Чистайда яшәүче Ходаковлар гаиләсеннән килде:

"Күптән эленеп торасыңмы?"

"Белмим, сәгатьне элэктерергә өлгермәдем".

Ә Арчадан Л.Җиһаншина исә безгә мондый дулкынландыргыч юллар җибәргән:

"Арча кичләре,
Сөю хисләре...
Чит хатыннар аулап, дускай,
Әллә нишләдем..."

Рәсемдә үзләрен танучылар да бар, күрәсең. Мәсәлән, Яшел Үзәннән Ю.Беляйчев болай дип язый: "Насыйп булып, исән калсам, әбизәтелне художникның ипи шүрлегеен җимерәчәкмен!"

Кайберәүләр ситуацияне заманчарак күрә. Екатеринбургтан Владимир Князев безгә мондый җавап юллаган:

"Бу салым инспекциясеннән кая качарга белгән юк, брат!"

Иң күп санлы җаваплар, әлбәттә, күт-ыштан тирәсендә булды. Без аларны билгеле сәбәпләр



буенча баса алмыйбыз. Ә менә Сарытауда яшәүче А.Идиятуллиннан килгән юллар безгә кызыклы тоелды: "Синең хәл җиңелрәк: алай-болай янгыр яуса, ышыкта ичмасам!"

Әгәр кайберәүләр, теләкләре булып та, конкурска хат җибәрергә өлгермәгәннәр икән, алар өчен В.Милейко тарафыннан ясалган яңа рәсем тәкъдим итәбез.

Сездән хатлар көтәбез. Конкурс дәвам итә!



16-17 БИТЛӘРДӘ БАСЫЛГАН «ЧӘЙХАНӘ»ГӘ ҖАВАПЛАР

РЕБУС

«Хатын азса, ир башына, түрә азса, ил башына.

БАШВАТКЫЧ

Рәсемне игътибар белән карасаң, бүлмә ишегенең эчкә таба ачылуын күрергә була. Димәк, шаһит стенадагы сәгатьне берничек тә күрә алмаган, һәм аның бу турыдагы сүзләре — ялган.

ЧАЯН

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
№ 9 (1443) 1999

Журнал укучының фикере редакция фикеренә тәңгәл килүе мөмкин.

Баш редактор
Р. ЗӘКИЕВ.

Редколлегия:
Р. АБЗАЛОВ, И. АЗИМОВ, А. АЛЕШИН (баш рәссам), В. БИБИШЕВ, Л. БОЧКОВА, М. ГӘРӘЕВ, В. КОСМЫЛИН, К. КӘРИМОВ (җаваплы секретарь), Д. МАЛИКОВ (Зәлфәт), С. ПРИВИНА, В. ФЕОКТИСТОВ, Р. ХӘЛИЛУЛЛОВ, П. ШАҺРАЙ (баш редактор урынбасары), А. ШУЛЬПИНОВ.

Журналга Татарстан һәм Россияда, СНГ (БДБ) һәм башка илләрдә язылырга була.

УЧРЕДИТЕЛЬЛӘР:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ГАЗЕТА-ЖУРНАЛ НӘШРИЯТЫ ҺӘМ «ЧАЯН» РЕДАКЦИЯСЕ

Журнал Татарстан республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлде.
Теркәлү саны — 81.

ЯЗЫЛУ ХАКЫ — БАЗАР БӘЯСЕНӘ ТИН, ЯГЪНИ 1999 ЕЛНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНА РФ КАТАЛОГЫНДА 31 СУМ 80 ТИЕН.
ТАТАРЧА «ЧАЯН»ның ИНДЕКСЫ — 73488.
РУСЧАСЫНЫКЫ — «ЧАЯН» («Скорпион») — 73489.

Айга ике тапкыр татар һәм рус телләрендә чыга.

Белешмәләр өчен телефоннар:
43-50-32, 43-27-93, 49-36-16.

© «Чаян», 1999.

Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясендә басылды.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
1923 елдан чыга.

Басарга кул куелды 30.06.1999 ел.
Тираж 10763. Заказ 3- 309 .
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Басма табагы 2,1. Учетн.-изд. табагы 3,01.

«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2. «Чаян» редакциясе.

С.ПРИВИНА рәсеме.

— Атып та тишә алмаслык жилетлардан калган поскаклардан тегелгән киемнәргә үләрдәй булып чират торалар!

О.МИХНУШЕВ рәсеме.
(«ПЕРЕЦ».г.КИЕВ.)

— Кәчтүмгә берничә ямау сал әле: бүген салым инспекциясенә барасы бар...

Э.ДЫШАЕВ рәсеме.

С.ПРИВИНА рәсеме.

В.ЛЕПХАНОВ рәсеме.



В.ИЖБОЛДИН рәсеме.